РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«6» май 2020 ел г. Альметьевск № 584

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«Әлмәт муниципаль районы
муниципаль махсуслаштырылган
торак фондының хезмәт торак
урыннарын бирү тәртибе турындагы
нигезләмәне раслау хакында»
2013 елның 30 маендагы 2186 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Хокукый мониторинг тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондының хезмәт торак урыннарын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 30 маендагы 2186 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 14 августындагы 1476 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кararга 1 нче кушымтада:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Әлмәт муниципаль районының авыл җирлекләре территориясендә урнашкан хезмәт торак урыннары, әлеге авыл җирлекләре территорияләрендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, вазыйфаи бурычларны үтәү чорында анда яшәү хокукы белән, эшкә урнашуга ихтыяҗ булган гражданнарга (җирле үзидарә органнары, сәламәтлек саклау идарәсе һәм мәгариф идарәсе эшчәнлеген тәэмин итүче белгечләргә) бирелә.».

2. «Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондының хезмәт торак урыннарын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 30 маендагы 2186 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 гыйнварындагы 66 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга,

Зак. № 305-2000

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ